РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИК-УТЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИК-ҮТИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01 март 2023 ел № 6

Карарга үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 20 сентябрендәге 947 номерлы «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары, «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы карары нигезендә, Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районының Бик-Үти авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 18 декабрендәге 11 номерлы «Буа муниципаль районының Бик-Үти авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү һәм янгын сүндерү максатларында су алуга шартлар тудыру» карарының 1 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең торак пунктларында, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йортлар территорияләрендә гомуми файдалану җирләрендә махсус бүлеп бирелгән һәм җиһазландырылган урыннардан тыш азык әзерләү өчен ачык уттан файдалану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән басылып чыгарга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

Бик-Үти авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе Р.З. Җәләлетдинов